**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«15» август 2025 ел** **№ 312**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2019 елның 10 октябрендәге 241 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178 - ФЗ номерлы Федераль законга «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 20 мартындагы 35 - ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КА**РАР ИТТЕ**:

1. Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2019 елның 10 октябрендәге 241 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.4. Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, 1_1, 5, 9 һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлардан тыш, «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта әлеге карарлар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә урнаштырылырга тиеш.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев